Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

ЧАЯН



9

САТИРА һәМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ СЕНТЯБРЬ * 2023 * КАЗАН



Александр АЛЁШИН

Алмаз ХӘМЗИН

СЕНТЯБРЬ ҖИТТЕ...

Үтә гомер, чаба гына –
Күзгә кереп барабыз.
Кемдер туа, кемдер китә,
Сизмичә дә калабыз.

Уйлар туа төрле-төрле –
Бармы минем кирәгем?
Кирәк булсам ник үтәлми
Үтәләсе теләгем?..

– Их! Нигә болай итмәдем,
Ник шулай эшләмәдем?..
Икенче төрлерәк итсәм,
Болай яшәмәс идем...

Ах, диябез, уфтанабыз,
Сызланабыз ялгыштан.
Гомеребез кире кайтмас
Аккан су күк ялгыштан.

Уф, диябез көнчелектән,
Карап ятлар яшәвен.
Үзебездә теләк тумый
Күреп алар яшьнәвен.

Мәсәлләрдән гыйбрәт алыр
Башыбыз да юк мәллә?
Чикерткә кебек җәй буе
Сайрый торган без хәлдә.

Ходайга ялварып кына,
Аннан күтәп игелек,
Көч түкми генә яшәүче
Түгел идек без элек.


Андый түгел без хәзер дә,
Хезмәтебез кадердә.
Тик эшләгән байлыгыбыз
Китә әллә кемнәргә...

Басу-кырда иген – диңгез,
Тулып тора башаклар.
– Безне кая илтәр икән
Бу – бар сыман шатлыклар?
– Без бернәрсә әйталмыйбыз,
Ансын көйли башлыклар.

Балалар мәктәпкә бара
Белем алыр максатта.
Күңелләре күтәренке –
ЕГЭ бетәр форсатта!

Уңыш тулыр амбарларга,
Тыныч булыр дөньялар!
Быел сентябрьдә, бәлки,
Чынга ашар хыяллар!..

Игорь КИЙКО



Илдар НӘФИЕВ



ШОМБАЙ болай диде...



Хөрмәтле Чаян! Соңгы вакытта космос тирәсендә ниндидер ыгы-зыгы күзәтелә. Галәм киңлекләрен дисгәләгән илләрнең ракета-спутниклары айкый. Күптәннән көтелгән чит планета вәкилләре белән контактка да озак калмагандыр инде...

Л. КӘРИМОВА

АЛАБУГА

Укучыбызның хаты Шомбайны бик кызыксындырды.

– Сәер нәрсә, – диде аксакал, **– җирдә акыллы тормыш төзү урынына, без аны һаман күктә табарга телибез.**

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР

Яшьләр начар киңәшләргә ешрак колак сала.

Бик сирәк кеше бүгенге көн белән яши, күбесе соңрак яшәргә җыена.

Кешене иң нык картайткан нәрсә – хәзерге яшьләрдән зарлану.

Мин шаржларда гына чибәр булып чыгам.

Яшь тирес корты булу – карт оҗмах кошы булуга караганда хәерлерәк.

Барча кеше дә озак яшәргә тели, ләкин беркем картаерга теләми.

Дарулар кешегә авыруларга караганда акрынрак тәэсир итә.


Кеше авырулардан түгел, ә яшәгәннән үлә.

(Яшьлек-картлык белгечләре мәҗлесендә язып алынды.)

“Бисмилла...” – дип
башлыйк әле
әйтер сүзне.
Пәрвәр эшкә, мәслихәткә
өндим сезне:
Көләч булып калыйм дисәң,
һаман да син –
Таян, дустым, үзебезнең
“Чаян”га син!

Рашат НИЗАМИ

Вячеслав ШИЛОВ





Александр ШУЛЬПИНОВ

АНА КАПИТАЛЫ тирәсендә УЕННАР

Мошенниклар – законнарны белү буенча җәмгыятьнең иң алдынгы өлешедер. Гамьсез яшәргә ияләнгән тар карашлы кешеләрдән аермалы буларак, алар бөтен үзгәрешләр һәм яңалыкларны күзәтеп торалар, чөнки аларның матди хәле һәм законсыз табышлары моның белән турыдан-туры бәйле. Тормышта аферистлар аяк басмаган бер генә өлкә дә юк диярлек. Алар, әлбәттә, ана капиталын да читләтеп узмыйлар.

Татарстанда яшәүче бер ханым ана капиталын үзләштерү буенча киң колачлы операция үткәргән. Үзе кебек мошенниклар белән бергәләшеп, "әнкәйләр акчасы"на Кырымда торак алырга теләүчеләрне төп башына утырткан. Нәтиҗәдә, 535 кеше барлыгы 197 миллион сумнан колак каккан.

Тукай районыннан яшь ана матди хәлен шул ук "әнкәйләр акчасы" ярдәмендә төзәтергә теләгән. Ата-анасы йортының өлешен сатып алып, ул аны акчага әйләндерергә карар кылган. Ләкин яллаган риелторның планнары башкачарак булып чыккан. Ул да бу карарны тормышка ашырырга теләгән, ләкин үз файдасына...

Хатын-кызлар – бик сак халык, һәм үз акчасын чит кешегә ышанып тапшырырга атлыгып тормый. Кайбер сертификат ияләре аны үз көчләре белән кыштырдавык кәгазьләргә әйләндерергә тырышып карый. Казанда яшәүче бер хатын "торак шартларын яхшырту" максаты белән иске ерак авылда бушлай диярлек ташландык йорт сатып ала. Куркыныч кыяфәтенә карамастан, бу "торак"ның документлары тәртиптә була. Әмма "шартларны яхшырту" барып чыкмый, кулга төшкән акчаны да тиз арада кире кайтарырга туры килә.

Билгеле булганча, байны өтү бик кыен нәрсә. Аның каравы, һәрчак дәүләтне алдарга тырышып карау мөмкинлеге бар. Шул максат белән ике сылукай үзләрендә... виртуаль балалар булдыралар. Ялган туу турында таныклыкларны алар уңышлы гына Пенсия фондына тапшыралар һәм тиешле акчаны алалар. Ләкин "капиталист" булырга озак туры килми аларга. Ялган ачыла, һәм виртуаль аналар хәзер суд карарын көтәләр.

Ана капиталын дөрес файдалану – катлаулы нәрсә. Гадәттә аны ипотека аша торак сатып алырга тоталар. Фатирны тиз генә алып булмый – суммасы бик кечкенә. Бөтен банклар да андый клиентлар белән эшләргә ризалашмый, чөнки хуҗалар арасында бала бар. Тормышның кая борыласын беркем дә белми бит. Һәм кешеләр булдыра алганча җай эзлиләр.

Төрле вакытта ана капиталының мөмкинлекләрен киңәйтү турында төрле тәкъдимнәр булды – машина алырга рөхсәт итәргә, ана кешегә белем алу өчен тотарга, балага диңгездә ял итү өчен файдаланырга, процентлар белән банкка салып куярга. Әмма алар, законга җитәрлек дәрәҗәдә нигезләнмәү сәбәпле, барысы да кире кагылды. Өстәвенә, акчаны файдалануны күзәтеп тору мөмкинлеге юк, аның каравы, төрле жуликлар өчен юллар ачык кала. Әйтергә кирәк, шулай да соңгы вакытта йөгәнне бераз бушаттылар – торак реконструкцияләүгә рөхсәт бирелде, инвалид балаларга һәм өч яшькә кадәр балалары булган аз керемле гаиләләр өчен түләүләр кертелде. Дөрес, ул акча өчен җавап тоту үзе аерым бер башваткыч...


Соңгы вакытларда ана капиталы үзен акламады, илдәге демографияне үзгәртә алмады дигән сүзләр ишетергә туры килә. Бердәнбер нәтиҗәсе – көньяк республикалардан күчеп килгән гаиләләрдә бала саны артты. Белгечләр хәзер тормыш дәрәҗәсен күтәреп, кешеләргә онытылып беткән киләчәккә ышаныч белән карау тойгысын кайтарырга кирәк дигән фикергә киләләр. Ул чакта ана капиталы да кирәк булмас иде, ә аферистлар үзләренә башка шөгыль табарлар иде.

Людмила САФИУЛЛИНА



Валентин ДРУЖИНИН

Василий АЛЕКСАНДРОВ



Виктор ФЁДОРОВ



Валерий ТАРАСЕНКО





• • •

Доктор кабинетына авыру керә.

Ишек төбендә үк абынып егыла да аягын, кулын сындыра, башын яра, шулай булса да, докторның өстәле янына шуышып килә һәм болай ди:

– Доктор, мин сорарга гына теләгән идем...

• • •

– Тырышып эшләп хәллелекне ныгытып буламы?

– Әлбәттә... Инфаркт хәллелеген, шок хәллелеген, депрессия хәллелеген...

• • •

– Әти, син ничек уйлыйсың, Колобок дөрес эшләгәнме, әбисе белән бабасыннан китеп?

– Юк, билгеле, аны бит ашаганнар.

– Аны әбисе белән бабасы барыбер ашаган булырлар иде, ә болай ул, ичмасам, дөнья карап йөргән.

• • •

Интернетта “Кеше яшәми торган утрауга үзегез белән нинди китап алыр идегез?” дигән сорау күрсәм, күз алдыма мондый хәл килә: батып бара торган лайнер, акырышулар, паника, барысы да коткара торган шлюпкаларга йөгерә, ә мин акылдан шашардай кешеләр төркемен ерып, кемнеңдер кулын чытырдатып тотам да колагына кычкырам: “Гафу итегез, әйтегезче, китапханәгә ничек барырга икән?” – дим.

• • •

Ишеткәнем бар, бик стильле хатынкызның аяк-киеме һәм машинасы бер төстә булырга тиеш. Үземә кызыл читек сатып алдым әле, утырып йөри торган маршрут автобусыма туры килсен дип.

• • •

Чубайс Грециядә... Явлинский Лондонда... Пугачёва Израильдә... Менә күрәсез, барысы да чыгга ашты: Рәсәй пенсионерлары дөнья буенча сәяхәт кылып йөри.

• • •

Ике табиб сөйләшә:

– Беләсезме, минем белән шундый очрак булды: бер пациентым диагнозы буенча ун ел элек үләргә тиеш иде, ә ул һаман яши.

– Күрәсезме, әгәр кешенең чынчынлап яшисе килә икән, монда медицина да көчсез.



Рашат НИЗАМИ

ҖӨМЛӘЛӘР

- Ялганчының акылы – кыска, теле – озын.
- Ватык кыңгырауның тавышы да ватык чыга.
- Көчле сүзләр көчле фикер тудыра.
- Битеңне бизәү белән мавыкма, акылыңны бизә!
- Мәхәббәтнең формуласы: тормыш – сәхнә, катнашалар икәү, финал – бәхет яки бәхетсезлек.
- Болын яме – чәчәк белән, мендәр яме – кыз белән...
- Маймыл белән ишәккә китап тоттырмыйлар.
- Чүпләмәгез Җирне! Җир бәләкәй генә ул.
- Гаҗәп хәл: Дөреслек белән Ялган арка терәшеп яши.
- Юләрлеккә кайчагында бер адым да җитә...
- Тырнак очы хәтле нәни бөре кышкы салкыннарга ничек түзә икән – ни пәлтәсе, ни бияләе юк.
- Алтын теш куйдырып кына авызыңнан алтын сүзләр чыкса икән ул!
- Чәрелдек хатыннан ерак тор!..



Николай ВОРОНЦОВ



Константин ЧАХИРОВ



Сергей АНДРИАНОВ

Виталий ВЕСНИН

Вундеркинд

Шулай, бервакыт, миңа эшләр буенча бүтән шәһәргә барырга туры килде. Акча янга калсын дип, плацкарт вагонга билет алдым. Өске сәндерәсенә туры килде урыным. Ярый әле күршеләрем яхшы кешеләр булып чыкты, ә калган урыннар купеда: гаиләлеләр, үзләре белән алты яшьлек уллары да бар. Ямансулап бармас өчен сканвордлы журнал алган идем. Кичкә таба, шуның берничә кызыклы гына язмаларын укып арыгач, "башваткыч"ларын чишәргә тотындым. Нәтиҗәдә, шуларның яртысы чамасын чиштем, ә калганнарына физикадан, географиядән, әдәбияттан тирән белем булуы кирәк иде. Җиңелүемне танып, журналымны өстәл өстендә калдырдым да үземнең өске ятакка менеп яттым. Шулчак теге малай, эшсезлектән интеккәнгәме, сорап куйды:

– Ә миңа сезнең журналны карарга мөмкинме?

– Әлбәттә! Сканвордларны да чишәрсең бәлки! – дип шаяртып алдым да йокыга талдым.

Иртән, юлдашларым вагоннан төшәргә әзерләнгәндә, йокы аралаш әлеге дә баягы малайның тавышын ишеттем:

– Әни, мин сканвордның бөтен сорауларын чиштем! – диюен.


– Вәт әйбәт булган! – дип мактап куйды аны әнисе. – Хәрефләрен дә матур итеп язгансың, мәктәпкә әзерлегең күренеп тора!

Йокым шундук качты. Алты яшьлек бала минем кебек югары белем алган кешедән өстен булсын әле! Кызык, каян белә ул инглиз галиме ачкан тыгыз матдәләрнең деформация законын? Чыннан да, бөтен шакмаклар тутырылып беткән бит. "Бәлки, журнал ахырында җаваплары булгандыр?!" – дип уйладым мин, тиз генә аска төшеп, журналның соңгы битләрен актардым – җаваплары юк.

"Вундеркинд! – дидем мин үземчә йомгак ясап, үземне сүгә-сүгә. Йөрәк чәнчеп куйды. – Ярар, карыйк әле, җаваплары нинди икән?!"

Һәм шунда миңа барысы да аңлашылды, кәеф тә күтәрелеп китте, җиңел сулап куйдым, эш шунда икән: чишә алмаган сүзләрем буталчык рәвештә хәрефләр белән тутырылган. Малай өчен бу уен булган – "бөтен буш шакмакларны теләсә-нинди хәреф белән тутыру".

Максим СМАГИН





БЮДЖЕТ БҮЛЕГЕНӘ – АКЧА ТҮЛӘП

Медицина колледжы директоры Зөһрә Хисаметдинованы абитуриентлардан ришвәт алуда гаеплиләр. Бюджет бүлегенә гарантияләнгән керү өчен, нәтиҗәләргә карамыйча, бу ханым 50 дән 100 мең сумга кадәр алган. Әлегә исбатланган очраклар дүртәү генә, ләкин, тикшерүчеләр фикеренчә, алар кимендә йөзгә якын чамасы булырга мөмкин. Аена 100 мең алып эшләүче җитәкченең өендә 17,5 миллион сум табылган, ә судка ул "Ягуар"да килгән.

КОМСЫЗЛЫКТАН ЧЫККАН КЫТЛЫК

Казан янындагы бистәләрдә чүп мәйданчыклары ясар өчен буш урыннар юк. Бөтен җир диярлек йортлар арасында бүленгән, тормыш эшчәнлеге калдыклары өчен юл чите генә калган, ә анда төзелеш тыелган. Өстәвенә, кайбер әрсезләр чүп контейнерлары торган урыннарны үз милекләре итеп рәсмиләштерәләр, ә соңыннан суд аша аларны юкка чыгарттыралар. Бу ысул белән инде 25 чүп җыю урыны югалтылган.

"АШЫКМАС ЯРДӘМ"

Чаллыда ашыгыч ярдәм бригадалары җитми. Гамәлдәге нормативлар буенча, шәһәрдә һәм Тукай районында аларның саны барлыгы 60 булырга тиеш, ә чынлыкта исә 18 бригада гына эшли. Медицина хезмәткәрләренең саны да нормадан ерак – монда кирәкле табибларның бары тик 32 проценты, урта персоналның 68 проценты һәм машина йөртүчеләрнең яртысы гына эшли. Мондый шартларда авырулар янына 20 минутта килеп җитәргә тиешле ашыгыч ярдәм машиналары сәгатьләр буе килергә дә мөмкин.

КОММЕРЦИЯ СЕРЕНЕҢ БӘЯСЕ

Казанда бер эшмәкәр чит кешеләр эшенә борынын тыкмакчы булган. Ир кеше 25 мең сумга ят фирманың персонал җыю буенча менеджерына клиентларының электрон базасын сатарга тәкъдим иткән. Менеджер ханым, озак уйлап тормыйча, бу турыда җитәкчесенә хәбәр иткән. Эшмәкәр белән менеджерның аралашуы полиция күзәтүе астында дәвам иткән. Коммерция сере өчен акча тапшырган чакта эшмәкәрне тоткарлаганнар. Сернең бәясе дә билгеләнгән. Ул да булса – кузгатылган җинаять эше.



Игорь КИЙКО



СЕЗ БЕЛӘСЕЗМЕ...

• Иң зур «бөке» Кытайда барлыкка килгән. 100 километр озынлыктагы юлны 5 көн буе үткәннәр, һәм бу хәл 12 көн дәвам иткән.

• Дөньядагы беренче юл кагыйдәләре авторы Уильям Фелпс Ино беркайчан да руль артына утырмаган булган.

• Автомобильдәге куркынычсызлык мендәрчекләре пуля тизлеге белән ачыла.

• Фольксваген автомобильләр генә түгел, сосискалар да җитештерә.

• Дөньяда беренче тизлек арттыру өчен штраф 1902 елда салынган: гаепле машина йөртүче сәгатенә 70 километр белән «очкан».

• Ел саен 60 миллион автомобиль җитештерелә. Бу – көненә 165000, сәгатенә 6875 һәм бер минутка 115 машина дигән сүз.

• Хәзер дөньяда 1 миллиард автомобиль эксплуатацияләнә. Димәк, Җир шарында яшәүче һәр җиде кешегә бер машина туры килә.

• Сәгатенә 100 километр тизлек белән машинага утырып Айга барып җитәр өчен ярты ел вакыт кирәк булыр иде.

• Тизлекне арттырган өчен (290 км/сәг) иң зур штраф Швециядә салынган. Ул 1000000 евро тәшкил иткән. Шведларны тизлек арттырган өчен, хезмәт хакларына пропорциональ рәвештә штрафка тарталар.



Сергей АНДРИАНОВ

• • •

Автоинспектор җиңел машинаны туктата:

– Штраф түлә!

– Нәрсә өчен? Мин бит бернинди кагыйдәне дә бозмадым.

– Бозмасаң ни! Минем гаиләм синең кагыйдә бозганыңны көтеп утыра алмый!

• • •

Инспектор хәтәр җилдереп килгән машинаны туктата.

Рульдә хатын-кыз утыра.

Тәртип сакчысы кырыс кына:

– Ханым, сез нигә тизлекне арттырасыз? Штраф! – дигән.

– Беләсезме, инспектор әфәнде, мин машинаны бик начар йөртәм. Ялгыш берәрсен таптатмагаем дип, тизрәк кайтып җитәргә ашыга идем.

• • •

Инспектор – шофёрга:

– Билгене күрмәдегезмени? Бирегә бер якка гына барырга рөхсәт ителә.

– Нәрсә, мин ике якка бара идеммени?

Дамир МОРТАЗИН



Казанга эш белән килгән идем. Кирәк бит, шунда балачак дустым Рәхимне очраттым. Мин аны инде мәктәп елларыннан бирле күргәнем юк иде. Бераз тазарып киткән дип әйтимме, баш түбәсе дә ялтырый башлаган. Элеккеге чытлыклылыгы кимегән, карап торганда аның клубта кызлар белән парлашып биеп йөргән шактый кыю егет булганлыгын тоймыйсың да.

– Хәлләр ничек, дускай? – дип очрашуга ук сәлам бирдем.

– Тауга таба бара! Әле күптән түгел генә Боровойда йорт җиткердем. Озакламый, Алла бирса, гаиләм белән шунда күчәрбез. – Рәхим игътибарын миңа юнәлтте дә минем әлләни шаккатмаганымны сизеп, өстәп куйды. – Безнең әле шәһәрдә дә фатирыбыз бар – шәп планировкалы... Әле эшемдә дәрәҗәмне күтәрделәр – хәзер министрлыкта хезмәт итәм... – диде.

Ул беркадәр тәкәбберлек белән миңа таба карап:

– Ә син ничек? Авылда батып калдыңмы? – дигән булды.

Мин инде ялганлый белмим, ләкин бу очракта гөнаһ дип тормадым:

– Инде күптән шәһәрдә яшим, – дип алдадым.

– Фатирсыз, акча түләп, кешенекендә торасыңмы? – диде Рәхим, исе китмәгәндәй.

– Үземнеке! – дидем мин тавышыма горурлык өстәп.

Рәхим сагаеп калды.

– Хрущёвкадамы? – ди.

– Яңа йортта, – дидем мин. – Казансу ярында...

– Бер бүлмәледәме? – диде ул мыскыллап.

– Өчле, икеяссылыкта...

Яшьлек дустым дерелдәп куйды. Аның йөзе мыскылланган төс алды.

– Эшкә дә якын. Мин бит хәзер нефть компаниясендә – инновация һәм цифровизация бүлегендә, мөдир. Эштән бирелгән машинам бар, бонуслар, дивидентлар... Үзең беләсең...

– Дивидендлар... – дип, каушап пышылдады Рәхим.

– Шунда ук хатынымны да урнаштырдым. Әлбәттә, авылдагы барлык туганнарымны да компаниягә тарттым. Сеңлем аспирантураны тәмамлый, бер төрек бизнесменына кияүгә чыгарга чамалый...

Яшьлек дустым агарып катты, күзләрен йомып, авызы белән һава йотарга тотынды.

– Тиздән әти-әнием дә минем янга торырга киләчәк. Яңа фатирда ремонт ясап кына бетерим дә...

Рәхимгә каравы да куркыныч булып китте. Ул йөрәген тотып, аягыма килеп сыланды. Мин аны тотып калдым да, колагына кычкырдым.

– Рәхим, гафу ит, мин шаярттым! Мин элеккечә һаман авылда яшим мин.

Аның күзләре чак кына ачылып куйды.

– Мәктәптә укытучы булып эшлим, – дидем.

Рәхим, хәлгә килеп, аягына басты.

– Әти-әнием, абый-энеләрем, сеңлем – барысы да авылда...

Балачак дустым кәчтүмен кагып, галстугын төзәтте.

– Ну шутник та инде син! – диде ул ныгыган тавыш белән. – Онытканмын, син бит мәктәптә дә барыбызны да алдап, көлдерергә ярата идең...

Вячеслав ШИЛОВ



Иван АНЧУКОВ





ҮЗСҮЗЛЕ УТЫН КИСҮЧЕЛӘР

Карачай-Чиркәсиянең полиция лейтенанты Аслан Хубьев эшләр ачуның процентын арттырырга исәп иткән. Ул Элтаркач авылында ике ир кешене тапкан һәм авыл читендәге ике зирек агачын кистерткән. Аннары ул шунда ук кылынган җинаять турында кәгазьләргә кул куярга кушкан. Ләкин агач кисүчеләр полиция хезмәткәре күздән югалугa, шикаять белән хокук саклау органнарына ашыкканнар. Җинаять кайнар эзләр буенча ачылган.

ЧИТ ИЛ СПЕЦИАЛИСТЛАРЫ

Европа, мигрантлар камыты астында сулыш ала алмаганда, Россиядә чит ил «белгечләре» агымы күзәтелә. Демографлар әйтүенчә, таҗик мигрантлары гына 3 миллионнан артып киткән. Таҗикстанның бөтен халкы да 10 миллион гына, ә аның өчтән бере диярлек Россиягә килеп урнашкан. Ләкин кискен зәгыйфьләнгән рубль кире процесска китерергә мөмкин – хезмәт мигрантларының үз ватаннарына кучүенә.


БИШЕНЧЕ АРТЫК

Ставрополь өлкәсенең Пятигорский авылында бер гражданин юл хәрәкәте полициясе рәтенә кергән. Полиция капитаны формасы кигән 48 яшьлек эшсез һәм дүрт юл инспекторы белән бергә машина бозучыларны туктаткан. Чираттагы полициянең видеоязмасын тикшерү вакытында бишенче артык кеше күренгән. Ялган патрульгә штраф яный, ә менә аның «хезмәттәшләре» җинаять җаваплылыгына тартылачак. Күкрәк билгесен каян алганлыгын тикшерү ачыклаячак.


УҢАЙСЫЗ БҮЛӘК

Шотландиядә паралимпия буенча Дөнья чемпионатында балачактан ук терсәккә кадәр кулы булмаган Испания велосипедчысы Рикардо Тенга бүләк итеп кул сәгате тапшырылган. Спортчы үзе бүләккә юмор аша караган. Авырлыклар аны куркытмый, шуңа күрә паралимпия уенчысы сәгатьне терсәкнең өске өлешенә таккан.

Валерий ТАРАСЕНКО



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Евгений БУГРОВ

Күрсәтербез әле без аларга!

Яратам мин үзебезнең ишегалдындагы яшәүче кешеләрне – барысы да бер гаилә кебек. Нәрсәдер эшләргә кирәк булса – шундук үтәп куялар. Билгеле, һәркем үзенчә. Менә, мәсәлән, сайлаулар. Әйе, сайлауга хәтле ике айлап алдан барысын да уртага салып киңәшәбез һәм кирәкле вакытына әзерләнеп тә куябыз. Сайлаулар бит – җитди нәрсә, ул теге 71 нче фатирдагы ире исереп кайтып тавыш куптаручы җәнҗал гына түгел. Һәм 18 нчедәге хатыны ирен башка кеше хатыны белән тотып, разбой салу вакыйгасы да түгел. Сайлау – бөтенләй башка мәсьәлә. Чөнки һәркемнең җанында кайнап чыккан, барысы да шуны төзәтергә маташкан хәлләр – алар бит бик күп җыелган. Сайлау җиткәч, без аларны барысын да әйтәчәкбез һәм кайда кирәк, шунда тыгачакбыз! Тегеләй-болай гына түгел!..

Без хәтта үткен сораулар списогын да алдан әзерләп куйдык. Эскәмияләргә чыгып утырып, бергәләп уртаклашабыз – кем нәрсә ишеткән, кем нәрсә интернетта укыган... Бер сүз белән әйткәндә, барысын телеп, кирәген биреп, анасын искә төшереп чыгабыз!

Иң кайнар тема – ЖКХ. Кырып-себереп талыйлар, әйтерсең лә торбаларын Марстан йә Юпитердан сузганнар. Әле канны кыздыра торган медицина темасы бар. Ни өчен бәяләр үсә, әйтерсең лә эпидемия вакытындагы температура. Температура кебек булса, мәсәлән, ул бит рәтләнә, төшә, ә менә бәя дигән нәмәстә, нигәдер, күтәрелә дә төшми генә, шул урында кала. Кибеттәге бәяләрне әйтергә дә кирәкми – анда, күрәсең, һәрвакыт ниндидер ярышлар үткәрәләр. Менә, әйтик, сөт кыйммәтләнгән, димәк, доллар сикергән, чөнки печән турыдан-туры долларга бәйле.

Менә шулай, боларны ныгытып һәм шәп итеп бер киңәшкә килеп, барыбыз да бер булып билгеләнгән көнне бөтен мәсьәләләрне җыеп, һөҗүмгә күчәчәкбез, ачсыннар гына сайлау участокларын.

Өч көн алдан бөтен ишегалды халык мәнфәгатьләрен кайгырту анты белән шау-гөр килеп тора.

– Карале, Маннур абый, сайлауга барасыңмы?

– Ничек бармаска инде?.. Җитәр! Халык мәнфәгатен кайгыртучыларны сайларга кирәк!

– Иң кирәклесе – безнең бердәм булу!

– Ишеттек, анда күзәтеп торучылары да була икән, димәк, тегеләрнең тавыш урлашулары барып чыкмаячак!

Шулай итеп, безнең бөтен ишегалды хәлиткеч һөҗүмгә әзер, сайлау өере үзенең иң көчле вакытына җитә, ә эскәмияләрдәге сөйләшүләр инде бөтенләй бүтәнчә.

– Нәрсә, сайлауга бардыгызмы?

– Минем бүтән эшем юк идеме әллә: бакчадагы эшемне кем карар?

– Әй лә, анда бару нәрсә бирә: бардың ни, бармадың ни, барыбер алар үзләренекен эшли...

– Анда баруның бер файдасын күрмим...

– Ирем балыкка китте... Берүзем нишләп барып йөрим ди?

Аңлашыла, бу юлы да бернәрсә дә килеп чыкмады. Ләкин мин ни өчен яратам үзебезнең ишегалдын, чөнки ул беркайчан да төшенкелеккә бирелми һәм өметен дә өзми.

– Әнә, теге, безгә килгәч вәгъдә бирүче... Килеп киткән, диләр... Бәлки нәрсә булса да үзгәртер безнең ишегалдындагын...

– Нәрсә син, һаман шул бер нәрсәне кабатлыйсың? Сайлау тагын була әле ул... Бер генә көн яшәмибез. Киләсе сайлауларда күрсәтербез әле без аларга! Шулаймы, күрше?

Михаил ЛАРИЧЕВ



Вячеслав ШИЛОВ



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Виктор ВЕСЕЛОВ

Өй залиме

Трамвай көтеп торам. Янәшәмдә ике хатын-кыз. Берсе икенчесенә әйтә:

– Мин үземнекен менә болай тотам! – ди, йодрыгын төйнәп.

– Минеке пысылдый да алмый! – дип мактана икенчесе.

Минем гаиләдә алай түгел. Мин бит төзүче. Төзим. Хатынымны һәм өйдәгеләрне. Өйнең бусагасын атлап керүем була – балалар өстәл астына, песи – карават астына, тутый кош – люстрага кача. Хатынымның әнисе – әби – башмакларымны кулына тоткан килеш каршы ала...

Үземнекеләрне яратам, аларны кайгыртам. Хатынымнан сорыйм: "Сиңа туган көнеңә нәрсә бүләк итим?" – дим. Колагына күрсәтә. Аңладым, җүләр түгемен. Телисең икән – ал: мамыклы таякчыклар, минем һәр сүземне ишетеп торсын өчен.

Әби укырга һәм тәмле-томлыны ярата. Аның теләген укмаштырдым. "Сироптагы елан" дигән детектив тәкъдим иттем.

Балаларга укырга булышам. Өстәл астыннан чыгуга, китапларына тотыналар. Улым гел "бишле"гә генә быелгы уку елын тәгәлләде.

Хатын болай ди:

– Әйдә, улыбызга мобильник бүләк итик, тырышты бит!

Уйлап тапкан! Аның белән хәзерге заманда кемне шаккаттырасың? Классларында гына түгел, бөтен мәктәпләрендә булмаган счёт бүләк иттем! Кирәкле әйбер, башны эшләтә. Ул хәзер кубик Рубикны сул аягындагы бармаклары белән җыя. Калькулятор кебек башы белән чутлый. Сораган идем: "245 не 347 гә тапкырлагач ничә була дип? Шундук җавап алдым: "85015". Кәгазьгә язып тикшереп караган идем, баганалап, дөрес! Кызларым белән авыррак, тыңламыйлар. Кыз әйтә:

– Уку түгел, – ә иң кирәге – чибәрлек һәм фигура. Ул чакта кияүгә дә уңышлы чыгасың!

Аңа әнисенең көндәлеген күрсәттем.

– Кара, әниең мәктәптә ничек укыган: математика – "икеле", рус теле – "икеле", әдәбият – "өчле"... Шуңа күрә ЗАГСка минем белән китте. Кемгә кирәк ул "икеле"гә укыган кыз?!

Кызга юри, алыштырып, үземнең дневникны күрсәттем. Хатыным, ничектер, болай дип әйткән иде:

– Японциядә шундый закон бар: әгәр ир үзенең ир бурычларын үтәмәсә, хатыны аерылышырга хокуклы икән. Бу сәбәп шулхәтле дөрес итеп санала, тикшереп-нитеп тормыйча, шундук аералар ди. Бездә дә шулай булсачы!

– Син, – дим, – бу мәсьәләдә үпкәләрлек түгел. Нәкъ кешеләрчә – айга бер.

– Ә алдарга?! Айнымыйча эчкәндә, синең ай буе – "критик көннәрең"...

– Мин бит зур бәйрәм көннәрендә генә эчәм!


– Ә кичә нинди идең? Нинди бәйрәм?

– Гвинея-Бисау оештырылган көн.

Хатын белән шундый авыр көннәр була. Ә менә әби – алтын! Кадеремне белеп яши...

– Кияү балакаем, хәзер бөтен нәрсә кыйбат, аяк киемеңне саклап ки. Кышкы итегеңнең табанын дуңгыз мае белән сыла яисә май белән сөрт. Озакка чыдар! – ди.

Травматологиядән чыккач, аңа чәчәк бүләк итәм әле!



Виктор ФЁДОРОВ

Игорь КИЙКО



Валентин ДРУЖИНИН



Максим СМАГИН



Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Кайсы җен әйбәтрәк?

Соңгы вакытта автобус тукталышларындагы электрон язмалар югалды. Халык борчыла: автобус-трамвайның кайчан килүен белә алмыйлар.

– Күпме вакыт әрәм булды, тукталышта автобус көтеп, чак кына эшкә соңга калмадым, – диде кичен кызы.

– Мин дә шулай, өйгә кайтканда, – дип җавап кайтарды кияве.

– Элек ничек йөрдек икән соң без, ул язмалар югында? – дип, әби сүзгә кушылды.

– Әби, ул язмалар булмаганда автобуслар да йөрмәгәндер? – дип әйтеп куйды оныклары.

– Автобуслары да бар иде, ләкин аның кайчан киләсен генә белмәдек. Озаклап көтеп тордык. Сезнең шикелле телефонга терәлеп түгел, китап укып, кешеләр белән аралашып, сөйләшеп.

– Без дә китап укыйбыз бит, – диде, тагын сүзгә кушылып оныгы.

– Сезнең китаплар кайда? Телефонда. Аннары, сез аны укымыйсыз, ә тыңлыйсыз гына.

– Аермасы нәрсәдә?

– Шунда. Озакламый хәрефләрне дә онытып бетерерсез, телефоныгыз белән.

– Автобуска керсәң, барысы шуңа текәлгән. Колакларына нәрсәдер тыкканнар да күзләрен акайтканнар. Кем кергәнен, урын бирергә кирәклеген дә уйламыйлар. Хитырыйлар...

– Әби, син элеккеге заманаларны искә төшермә инде. Алар үткән.

– Кире әйләнеп кайтса нишләрсез? Менә бит, тукталыштагы язманы күрмәгәч, вакытыгыз да озак үткән шикелле булган. Ә бит аларның расписаниесе үзгәрми. Китапны да кулыгызга алганыгыз юк. Китапханәнең кайда икәнен дә белмисездер.

– Әле алар эшлимени? – дип аптырап куйды онык.

– Эшли, ләкин сезнең кебекләр хәзер анда йөрми шул. Ә менә без үскәндә аннан кайтып кермәдек. Буш вакыт чыккан саен китапханәгә йөрдек.

– Нигә китап укырга? Хәзер бөтен китаплар буенча кино төшерәләр. Карыйсың да эш бетте.

– Юк шул, китап китап инде ул. Кино белән чагыштырып булмый...


Бернечә көн үткәч, оныгы, иртән торып, каядыр җыена башлады.

– Иртүк кая барасың, улым? – дип кызыксынды әбисе.

– Әби, дусларыма сөйләдем син сөйләгәннәрне – китаплар уку турында. Барыбыз да бүген, җыелышып, китапханәгә барырга булдык. Бәлки, безгә дә ошап, без дә китапны сезнең шикелле укый башларбыз.

Беркавымнан:

– Китап җене кагылу – телефон җененә караганда мең мәртәбә файдалырак ул, улым! – дип, әби кеше артларыннан сөенеп карап калды.



Виктор ИГНАТЬЕВ, 1973 ел.

– Шеф, ялгышлык! Сез түгел банкрот, ә конкурентлар!

Шагыйрь Хәмид Вәлиди минем күземә байтак еллар элек чагыла иде инде. Ниндидер сәерлеге булгангамы аның белән нык аралаша алмадым. Ул, татар кайда җыела, шунда сихерле таягы белән килеп чыга да, һәр төркемгә башын тыгып, көн тәртибендәге вазгыятькә анализ ясый башлый, серле карашы белән һәммә кешегә бәя биргәндәй, шундагы халәткә сеңә. Юкка түгелдер, тормышта нык сыналган, күпне күргән кеше буларак, затлы фикерләрен тезә башлый. Гадәттә, андыйлар "бездәй акыллыларга" әлләни ошап бетми шул. Баксаң, шагыйрь Зөлфәт, Наис, Мөдәррис, Харрас кебек бөекләр белән якын дус, иҗатташ булган шактый талантлы шәхес икән ул. Шул чорның бөек җырчыларын данлаган, талантларына гадел бәя бирә алган һәм иҗатын да мәдһияләгән зур шагыйрь – Хәмид Фәттах улы Вәлиди хәзер минем генә түгел, журналыбыз "Чаян"ның да якын дусты.

Шул очрактан аның бөек җырчыбыз Таһир Якупов истәлегенә язган шигырен тәкъдим итәбез.

КИРӘК БИТ ЧЫДАРГА...

Күп җырчылар булган сиңа кадәр,
Син киткәч тә шактый җырчы бар.
Ишетмичә Синең җырны, Таһир,
Күңел түзәр ничек, җан чыдар?!

"Олы юлның тузаннарын" бүген
Туздыралар бүтән җырчылар.
Сине көтә концерт саен күңел:
– Чыкмый калмас бүген, ул чыгар!

Тәмамланыр концерт, төшәр пәрдә,
Җырчыларга явар гөл-чәчкә.
..."Ак параход" сүз куйганмы әллә,
Безнең ярга килеп җитмәскә...

Яңгырый җыр, синең "Наласа"ң бу,
Күңелләрне урап моң ага.
Дулкын-дулкын тоташ җыр агыла,
"Күн авылы" ягына таба.

Кылганнарга сарылып җыр агыла,
Көзге яфракларны кочаклый.
Белсәң, Таһир, безнең сагынуларны,
Син көттермәс идең бу чаклы.

"Әдрән диңгез" буйларыннан кайтып,
Сәхнәләргә менәр идең дә,
Ялындырмый-нитми утызлап җыр
Җырлап бирер идең бүген дә.

Офыкларга китеп күмелдең син,
Җырлый-җырлый томаннар аша.
Кайтаваз күк безнең күңелләрдә,
Бертуктаусыз чыңлый "Наласа".







Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Тимер юл аркылы чыга торган юнәлештә бөке. Машиналар күп җыелган. Шофёрлар шлагбаум янына килгәннәр дә кайчан китеп буласын кызыксыналар. Будкадан стрелочник чыга да боларга болай ди:

– Җәмагать, бераз түзегез инде. Поезд өч сәгатькә соңга кала.

• • •

– Нәрсә ул откат?

– Ул – тендер билгеләгәндә нәкъ менә сезнең фирманы сайлап алганлыктан рәхмәт белдерүнең акчалата берәмлеге.

– Ә тендеры нәрсә?

– Анысы откат тармагындагы чемпионат.

• • •

Тараканнар атом сугышыннан соң да исән калачак, ә газета белән суксаң андый мөмкинлек юк. Бу хәл кәгазь масса күләм информация чараларының көчен тагын бер тапкыр исбатлый.

• • •

Хатыны – иренә:

– Сиңа кияүгә чыкканда сукыр һәм саңгырау булганмын!

– Менә, күрәсеңме, сине нинди авырулардан терелткәнмен.

• • •

Әгәр урынбасарлар җитәкчеләренең кызыкларыннан көлми башлыйлар икән, димәк, аны тиздән урыныннан төшерәләр дигән сүз таралган.

• • •

– Бу машина йөртүчеләрне әзерли торган мәктәпме?

– Әйе.

– Нинди машиналарда йөртәсез?

– Нинди машиналар булсын! Юлбашчылар әзерлибез!

• • •

– Лотерея билетлары сатып алыгыз! Төп приз – автомобиль!

– Кирәкми миңа ул. Мин җәяү йөрергә яратам.

– Ә сез барыбер алыгыз, барысы да отмый бит...

• • •

Пациент:

– Доктор, ә сезнең дипломыгыз чынмы?

Доктор:

– Әлбәттә, чын. Мин бит җүләр түгел, ялган диплом сатып алырга.



СӘНӘК БЕЛӘН СУГА ЯЗЫЛГАН КЕБЕК

Кадерле "Чаян"! Галимнәребез республикабызны су өстендә йөзә дип ышандыралар, янәмәсе, астыбызда галәмәт зур су катламы бар. Кая гына казынма, су бәреп чыга икән. Ә менә бездә юк андый хәл.

Суга кытлык авылыбызда гомердән килә инде. Элегрәк краннардан нәрсә булса да ага иде әле, коңгырт төсле булса да, ниндидер ис аңкыса да. Ә менә бу җәйне анысы да югалды. 80 нче елларда казып уткәрелгән су скважинасы тузып черегән. Эчә торган суны әлләни зур булмаган цистернада китерәләр китерүен, ләкин ул бөтен авыл халкы өчен – диңгездәге бер тамчы кебек кенә. Кемнәрнеңдер машинасы булса, суны күрше авылдан ташый. Район башлыклары, безнең суга сусаганыбызны белеп, яңа скважина бораууларга вәгъдә иттеләр итүен. Әлегә смета төзү мәшәкатьләре белән маташалармы, подрядчиклар эзлиләрме, әллә тагын акчалары да юкмы. Шулай итеп, яңа скважина барлыкка килүе суга сәнәк белән язылган кебек килеп чыга.

Калмия авылы халкы

ТУКАЙ р-ны

НОРМАСЫ БАР – РӘХӘТЕ ЮК


Хөрмәтле редакция! Безнең тормышыбыз норма буенча җайга салынган инде. Яшәү өчен мәйдан нормасы да, су куллануныкы да һәм айлык чүп-чарныкы да һәр кешегә бүленгән. Әле ишегалдындагы балалар мәйданчыгы уеннары да нормага кертелгән. Монысы балалар санына карап түгел, ә йорт-җир янәшәсендәге мәйданга карап билгеләнә икән.


Күптән түгел генә безнең ишегалдына ремонт ясадылар. Яңалык башкаруларыннан бик канәгать булдык, тик менә балалар мәйданчыкларыннан истәлек кенә калды. Шуның урынына бөтен яшьтәге балаларга исәпләнгән тауучыклар, таганнар һәм карусельләр, ягъни һәркайда урнаштырыла торган уен зонасы эшләделәр. Матур да булмаган исеме әлеге тутырылышка ятышып тора: спорт комплексы – монда баскычлар, таганнар (кечкенә тар утыргычлы, күкрәк баласы гына сыешлы) һәм ни өчен ясалганы билгесез – ялгыз өй. Бу рәхәтлек 14 подъездлы 9 катлы һәм 3 бишкатлы йортка чутланган. Аларда күп балалы гаиләләр яши. Хәзер инде безнең балаларыбыз башка ишегалларына качып уйнарлар, ә әти-әниләре аларны эзләп интегерләр.

Сөембикә урамындагы 6 нчы йортта яшәүчеләр

ТҮБӘН КАМА

Виктор ФЁДОРОВ









Равил Фәйзуллин 1943 елның 4 августында Балык Бистәсе районының Балтач (Юлсубино) авылында туган. Котлы Бөкәштә урта мәктәпне, 1965 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. Армиядә хезмәт итеп кайткач, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы аспирантурада укый. 1968–1972 елларда Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге җаваплы секретаре була. 1989 елдан – “Казан утлары” журналының баш мөхәррире. 1996 елдан – Татар ПЕН-үзәге әгъзасы.

Шагыйрь урта мәктәптә укыганда яза башлый. Шигърият мәйданына “Казан утлары”нда басылган “Нюанслар иле” дигән шигъри циклы белән чыга. Шуннан соң аның “Рәсем ясыйм”, “Аҗаган”, “Монологлар һәм диалоглар”, “Мәрмәр”, ”Гадиләргә гимн”, “Наз”, “Шигырьләр һәм поэмалар”, “Кошлар юлы”, “Якты моң”, “Җырларда ил гаме” һ.б. күп китаплары, 5 томлык сайланма әсәрләре дөнья күрде. ”Китаплары рус, башкорт, кыргыз, азәрбайҗан, чуаш, немец, поляк һ. б. телләрдә дә басылып чыкты.

Р. Фәйзуллинның күпчелек шигырьләре хәзерге заман кешесенә төбәп язылган, интеллектуаль укучыга адресланган. Тирән уй, фәлсәфи олы фикер, гражданлык пафосы – шагыйрь лирикасының төп асылын шулар билгели.

Ул җитмешенче еллардан башлап халык җырына нигезләнгән поэтик формаларны үзләштерүгә игътибарын көчәйтә. Сурәтләүдәге образлы фикерләүне индивидуаль үзенчәлеген саклаган хәлдә, ул бу юнәлештә дә яңа иҗади уңышларга ирешә.

Р. Фәйзуллин поэма жанрында һәм аеруча балалар поэзиясендә актив иҗат итә. «Көрәшчеләр» (1968), «Гадиләргә гимн» (1969), «Сәйдәш» (1981) поэмалары, балалар өчен язылган «Рәсем ясыйм», «Күмәч пешерүчеләр җыры», «Чәчәкләр үстердем», «Паласны кем кагар?», «Якты моң исемле шигырь китаплары шагыйрь иҗат эшчәнлегенең үзенчәлекле» бер өлешен тәшкил итәләр.

Равил Фәйзуллин әсәрләре берничә тапкыр төрле дәрәҗәдәге премияләр аерым алганда: 1966 елда яшь шагыйрьләрнең Мәскәүдә ВЛКСМ ҮК оештырган Бөтенсоюз фестивале премиясе, 1973 елда «Дружба народов» журналы премиясе, 1970 елда «Мәрмәр» исемле китабы өчен Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе һәм, ниһаять, 1978 елда (35 яшендә) «Шигырьләр һәм поэмалар» (1976) китабы өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнде.

Р. Фәйзуллин 1966 елдан – СССР Язучылар союзы члены.

ПЕНТАТОНИКА

Берзаман монгол илендә
булдык без кунакта.
(Моңарчы нигәдер юлым
төшмәгән бу якка).

Безгә дип концерт куйдылар
ерак бер аймакта.
Сәхнәдән агыла җанга
шундый якын көйләр!
әллә Сарманда утырам,
әллә, дим, Әлкидә!..

Идел шавын да ишетәм,
дала җилләрен дә...
Шул көйләрдә тибрәнә ди,
Кытай илләре дә!

...Җыр тәэсиреннән бер мәл
бу җир улы булдым.
Үзем сизмәстән, билләһи,
татар-монгол булдым.

БИЕКЛЕК

Тау өстендә наратлар
җилләрдә чайкалалар.
Очлары белән күкләргә
нидер язмак булалар?

Бөркетләр узышып яулый
күкнең яңа катларын.
Янәсе, киң офык күрсен
хакимлек канатларын!

Төнге күктән күп йолдызлар
атыла яна-яна.
Биектәнрәк төшкәне
күзләргә сеңеп кала.

Кеше дә үрләмәкче гел...
Ә рухының – үз күге.
Кылган игелеге белән
үлчәнә биеклеге.

АККОШЛАР

Фасил Әхмәтов көе

Күзләрдән соң язлар килми,
Алда — салкын, ак кышлар.
Китәсез дәмени,
Китәсез дәмени,
Китәсез дәмени, аккошлар?

Әллә ничек үтте яшьлек,
Соң очрашты язмышлар.
Хушлашырга безгә
Иртәрәк бит әле,
Иртәрәк бит әле, аккошлар!

Бездә әле бу дөньяга
Күңел тулы алкышлар.
Китәсез дәмени,
Китәсез дәмени,
Китәсез дәмени, аккошлар?

ӘНИ ИШЕТМИ КАЛГАН ҖЫР

Әни ишетми калган җыр
Бар күңелләрдән җылы,
Йомшак синең кабрең ташы.

Г. Тукай

Яшь чакта, сау чакта
дәрьялар, диңгезләр кичәргә
ишкәк тә, каек та табылыр.
Давылда адашсаң,
караңгы төннәрдә яктыртып
әнкәңнең йөрәге кабыныр.

Яшь чакта, сау чакта
даныңа, малыңа, җаныңа
дуслар да, ярлар да сарылыр.
Хәсрәткә тарысаң,
догада, күкләргә илереп,
тик газиз әнкәең сагыныр.

Яшь чаклар, сау чаклар,
болыттай, мәңгегә кайтмаска,
җилләргә сарылып агылыр.
Ахыргы көндә дә
чәчәкләр күзендә күрерсең –
әнкәең карашы чагылыр.

МЕТАМОРФОЗАЛАРДАН

• • •

Җан очты Күк бушлыгына.
Кабыгы калды Җирдә
кабер-түмгәк булып.

• • •

Тау убылып үзән-чокыр булды.
Түбән биеклекләр эзләп микән
йолдызлар төштеләр коеныргa
шаулап узган яңгырдан соң.

Мидхәт САДЫЙКОВ

ТОМНАР

Мәдинә татар гимназиясендә укый. Каникул вакытларында Казанга – әби-бабаларына кунакка килгән саен, аларның өйләрендә берәр төрле үзгәреш кертми калганы юк. Йә мебельләр куелышы ошап бетми аңа, йә кухнядагы шкафлар... Ни дисәң дә, булачак интерьер дизайнеры бит. Бу юлы да шулайрак килеп чыкты.

Чәйләр эчеп, әбисенең кайнар коймаклары белән сыйланып, күңелләре булганчы бер сөйләшеп алганнан соң ул, гадәттәгечә, залның идәнен юып алырга, тузаннарны сөртергә кирәктер дигән уй белән ваннага кереп китте. Аннан сулы чиләк, чүпрәкләр тотып зал ягына юнәлде. Уртасына олы телевизор урнаштырылган ике баганалы шкаф-купега карап бераз уйланып торганнан соң, идәндәге калын җәймәгә кырын ятып журнал укыган бабасына:

– Бабакай, буй җитмәслек өстәге шүрлектә тезелгән Александр Дюманың яшел тышлы унбиш томы, Вальтер Скоттның карасу кызыл төстәге сигез томы сезнең өчен бик кадерле китапләрмыни соң ул? Әйдә, алар урынына татар әдипләренең әсәрен урнаштырабыз.

Габделфәнис көтелмәгән мондый тәкъдимнән аптырап калды. Кулындагы журналын яткан көе генә китап шүрлегенә шудыргач, урыныннан кузгалып диванга күчеп утырды.

– Ни бит, кызым, заманы шундый иде бит аның. Юклык заманы иде. Аннары бик авырлык белән алынган әйберләр, мебель булсынмы, савыт-сабамы, китапләрмы – алар бик кадерле иде. Бу китаплар да танышлык аркасында гына кулга килеп эләкте...

Бабасы сөйләгән арада Мәдинә бер кочак Вальтер Скотт китапларын диванга китереп салды.

– Йәле, берәрсен ачып карыйк әле, ниләр турында икән дип, кулына эләккән җиденче томны ачып җибәргән иде, малай, аннан берничә яшел "өчлек" акча килеп чыкты. Алга таба бер кызыл "унлык", зәңгәр "бишлек"ләр һәм бер сары "берлек" диванга "очып кунды". Җәмгысы – 50 сум. Болар совет заманындагы акчалар иде. Алар Мәдинәнең яктырып киткән йөзенә кызыксыну нурлары өстәсә, бабасына – киресенчә... Ул урлашканда тотылган бала халәтендә иде. Кухня белән зал арасында йөренеп торган әбиләре дә әлеге манзарадан читтә кала алмады.

– Берәр нәрсә булдымы әллә? – дип, аларның янына килеп утырды. Күптәнге таныш акчаларны күргәч, ирен читләрендә елмаю чалымнары чагылып киткәндәй итте, аннары аларны кулына алып санап карады да, нидер исенә төшеп, иренә төкәлде. Тегесе:

– Карчык, минем гаеп юк монда, әнә Скотт бит, ни...

Мәдинә исә үз эшен белде: татар әдипләренең китапларын барлады, тузаннарын сөртте, зурлыклары, калынлыклары, төсләре буенча аларны аерып куя барды. Бераз тынычланганнан соң бабасы да аңа ярдәмгә килде, хатирәләрен яңартты.

– ...Шулай да без мәктәп елларында бик күп укый идек. Мин үзем, мәсәлән, алтынчы сыйныфта ук Г. Әпсәләмовның "Алтын йолдыз» романын укып чыккан идем. Китапларга карата мәхәббәт шул вакытта ук уянгандыр. Юкса бу чаклы китаплар җыелмас иде дия-дия, күренекле әдипләрнең әсәрләрен оныгына суза торды. Аннары алар бергәләп Г. Тукай, М. Җәлил, М. Мәһдиев, Ә. Еники кебек язучыларның китапларын шкафның иң югары киштәсенә матурлап тезделәр. Мәктәп китапханәсенә илтеп тапшырырга кирәк дигәннәрен аерып куйдылар. Шунда Мәдинә бабасыннан:

– Ләбиб абыйның китаплары сездә юкмы әллә, – дип сорап куйды.

– Бар. Балалар өчен язылганнарын әбиең үз шкафында тота. Укытучыларга хас булган гадәт буенча. Нигә аның исемен искә төшердең?

– "Илһам" Бөтенроссия яшь язучылар бәйгесендә мин дә катнашкан идем. Чаллы шәһәрендә узган очрашуга ул да килгән. Минем кайдан икәнемне белгәч: "Якташлар да бар икән биредә", – ди. Кызыксынып, төрле сораулар да бирде.

Онык белән бабай дөньяларын онытып китаплар арасында әвәрә килгән арада кич тә якынлашты. Бүлмәгә табада кыздырылган ризык исләре таралды. Көндез кыймаклар белән сыйланган булсалар, кичкә кыстыбый пешеп чыкты.

Бу юлы табын янында күбрәк әбиләре сөйләде. Аның инде бабасына булган ачуы "суынган", шулай да фикере теге акчалар тирәсеннән ерак китә алмый иде әле.

– Беләсеңме, кызым, ул вакытта бу акчага рәхәтләнеп ял итеп була иде. Бабаң, мәсәлән, 45 сумга турпутевка белән ун көн буе Латвиядә булып кайтты. Дөрес, аның яртысын профсоюз түли иде, шулай да... Менә бу бәләкәй генә сары "берлек"кә алты буханка ипи тия иде. Менә нинди заманалар бар иде...

Чәйләрне яңартып, кыстыбыйларны кайнарлатып сыйлана торгач, әңгәмә янә "китаплар дөньясына" таба авышты. Бу юлы Мәдинә сүз алды.

– Теге томнарны мин үзем илтеп тапшырырмын, бабай. Аннары татар теле укытучыбыз бу юлы да конкурста катнашуымны сорады. Бергәләп берәр хикәя язарбыз әле. Аның башлам өлешен яздым инде мин... азагы килеп чыкмый әле.

– Ярар, ярар, – диде Габделфәнис, оныгын юаткандай итеп. Андыйга әбиең оста инде, мин дә фикерләремне әйткәләрмен. Татар телен без дә күтәрешмәсәк кем күтәрер.

...Әлеге җылы җәйге матур кичтә, түгәрәк табын тирәсендә эчкерсез сөйләшеп утырган өч җан иясеннән дә бәхетле кеше бар иде микән?!



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 9 (1934) сентябрь 2023

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.

420047, РФ, РТ, Казан шәһәре,
Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.

Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.


«Журналга «Почта России» каталогы,
йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша
язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның
ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү
хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
типографиясендә басылды.
420066 РФ, РТ, Казан, Декабристлар ур., 2.
Чыгу көне: 01.09.2023 ел.
Тираж – 2632 Заказ С-2244

Редакциянең адресы: 420066, РФ, РТ, Казан, Декабристлар ур., 2.
Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!



Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Урта яшь нәрсә ул?
2. Балык тоту – сәнгатьме әллә спортмы?
3. Бәләкәй малайларның һәм кызларның өлкәннәрдән аермасы?
4. Өеңдә ялгыз булсаң нишләргә?
5. Агач буенча кайда көньяк, кайда төньяк икәнлеген ничек белергә?
6. Ни өчен компьютер шундый акыллы?
7. Халыкчан хатыннарча шаянлык?

ҖАВАПЛАР

1. Хатынының кая баруы барыбер – тик сиңа гына ияреп йөрмәсен. 2. Ират балык тотса – спорт. Балык тоту турыда сөйли башласа – анысы инде сәнгать. 3. Гадәттә, кызлар курчак ярата, ә малайлар – матур машина. Бу хәл унҗиде яшькә кадәр генә. Аннан соң – барысы да киресенчә. 4. Төнгә куркыныч кино карагыз, өйдә кемдер бар кебек тоелыр. 5. Чыршы – төньяк, пальма – көньяк. 6. Чөнки ул һәрвакыт үзенең ана платасын (материнская плата) тыңлый. 7. Үзе уйлап чыгарганга үзе үпкәли.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 8 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«СИН – ГОМЕР АГЫШЛАРЫМ»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Р. КАМАЛИЕВА (Сарман р-ны, Җәлил бистәсе),
А. УМЯРОВА (Мәскәү),
С. ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ (Казан).

Җиңүчебез – Җәлилдән
Розалия КАМАЛИЕВА!

БЕЗНЕҢ ВЕРНИСАЖ

Александр АЛЁШИН



Билгеле булганча, талантлы кеше бөтен нәрсәдә дә талантлы… Журналыбызның баш рәссамы Александр Алёшин – моның ачык дәлиле. Сәнгать белгече һәм рәссам, карикатурачы һәм китап бизәүче, кызык дүртьюллыклар авторы һәм яшь карикатурачыларның остазы… һәм, болардан тыш, бу көннәрдә түгәрәк датасын тотыручы юбиляр да. Быел 100 яшен тутырган журналыбызның һәм рәссамыбызның юбилейлары туры килү дә очраклы түгелдер. Котлыйбыз аларны!







4612750670080